КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 май г.Казань № 321

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 2 октябрь, 892 нче карары белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 2 октябрь, 892 нче карары белән расланган Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өлешле катнашу турында төзелгән шартнамәләре булмаган коммерциячел булмаган оешма милкендәге күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәяләүгә бәйле чыгымнар;»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«махсуслаштырылган оешманың коммерциячел булмаган оешма эшчәнлегеп документлар әзерләү һәм юридик әһәмиятле документларны Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру рәвешендә техник, хокукый яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук конкурентлы һәм конкурентлы булмаган сатып алулар процедураларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә бәйле чыгымнар.»;

7 пунктның бишенче абзацында «бурычлар» сүзен «йөкләмләр» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коммерциячел булмаган оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.»;

10 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_3$ – өлешле катнашу турында төзелгән шартнамәләре булмаган коммерциячел булмаган оешма милкендәге күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәяләүгә бәйле чыгымнар;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_4$ – Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында документларны әзерләү һәм юридик әһәмиятле документларны урнаштыру рәвешендә коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеген техник, хокукый яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук конкурентлы һәм конкурентлы булмаган сатып алулар процедураларын үткәрү буенча махсуслаштырылган оешманың хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә бәйле чыгымнар.»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_3$ – махсуслаштырылган оешма тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматларны, шул исәптән җитештерүче-оештыручыларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан һәм өлешле катнашу турында төзелгән шартнамәләре булмаган коммерциячел булмаган оешмалар милкендәге күчемсез мөлкәт объектларының күпфатирлы торак йортларны файдалануга тапшырганга кадәр һәм файдалануга тапшырганнан соң базар кыйммәтенә бәя бирүләр саныннан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларының базар кыйммәтен бәяләү кыйммәтеннән чыгып;»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$P_4$ – Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында документларны әзерләү һәм юридик әһәмиятле документларны урнаштыру рәвешендә коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеген техник, хокукый яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр

башкару, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә конкурентлы һәм конкурентлы булмаган сатып алулар процедураларын үткәрү буенча махсуслаштырылган оешманың хезмәт күрсәтүләр кыйммәтеннән чыгып; ул Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматларны, шул исәптән җитештерүче-оештыручыларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.»;

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Субсидия коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык һәм өстәмә хисаплылык (ул Килешүдә билгеләнгән очракта) тапшырылмаган очракларда;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсеннән тайпылуга пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә – субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгән очракта.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин